Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының
Баграж авыл җирлеге Советы

КАРАР

07.08.2020 № 183

"Физик затлар мөлкәтенә салым турында"
2014 елның 13 ноябрендәге 143 номерлы
Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге
Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 2014 елның 13 ноябрендәге 143 номерлы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 14 сентябрендәге 180 номерлы, 2018 елның 16 октябрендәге 128 номерлы, 2019 елның 27 мартындагы 143 номерлы, 2019 елның 18 ноябрендәге 167 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 1 пунктчасының өченче абзацында «бирелгән» сүзен һәм «дача» сүзен төшереп калдырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**Баграж авыл җирлеге**
**башлыгы** **П.Н. Минеев**